СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

___________________ с. Сарманово №_______________

29.07.2019 ел № 192

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен раслау турында

2003 елның 6 октябреннан 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2008 елның 26 декабреннан 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законы, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 20 апреленнән 324 номерлы “Башкару дисциплинасының торышы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан 2018 ел йомгаклары буенча халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен үтәү турында», «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (pravo.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хуснуллин

Кушымта № 1

Татарстан Республикасы
Сарман МР Советы карары белән
расланды
№ 192 29.07.2019 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ ТӨРЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕН АЛЫП БАРУ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Сарман муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару процедурасын билгели.
2. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге:

   а) муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылучы муниципаль контроль төрләре;

   б) муниципаль район территориясендә тиешле муниципаль контроль төрләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемнәре;

   в) о реквизитах нормативных правовых актов Российской Федерации, нормативных правовых актов Республики Татарстан, муниципальных правовых актов органов местного самоуправления Сармановского муниципального района, регулирующих соответствующий вид муниципального контроля

   Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актлары реквизитлары турында системалаштырылган исемлекне тәшкил итә.
3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
4. Исемлекне раслау, исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү, исемлектән мәгълүматларны төшереп калдыру Сарман муниципаль районы Советы карары белән рәсмиләштерелә.
5. Исемлектәге мәгълүматларга үзгәрешләр кертү яки исемлектән мәгълүматларны төшереп калдыру өчен Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирә торган хокукый нормаларның гамәлдә булуын туктату яки үзгәртү турында норматив-хокукый акт кабул итү нигез булып тора.
6. Исемлек алып бару түбәндәге форма буенча башкарыла.

Сарман муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару формасы

| № | **Сарман муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төренең исеме** | **Сарман муниципаль районы территориясендә тиешле муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органы исеме** | **Муниципаль контрольнең тиешле төрен җайга салучы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары реквизитлары** |
|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль торак контроле | Инфраструктура үсеше бүлеге | "Сарман муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру регламенты турында» Башкарма комитет җиәкчесе карары (№212 26.04.2016 – ред. №65 26.03.2019) |
| 2 | Автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү буенча муниципаль контроль | Инфраструктура үсеше бүлеге | “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру регламенты турында» Башкарма комитет җиәкчесе карары (№364 06.09.2018) |
| 3 | Тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсендә норматив-хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контроль | Инфраструктура үсеше бүлеге | “Сарман муниципаль районында тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру регламенты турында» Башкарма комитет җиәкчесе карары (№363 06.09.2018) |
| 4 | Муниципаль җир контроле | Район мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы территориясендә җирләрне файдалану буенча муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында" муниципаль район Советы карары (№73 28.05.2012) |